**Раслыйм:**

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль
районы башлыгы

Э.Н.Фаттахов

# ГАМИЛ АФЗАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ “ЯШЬЛӘР КАЛӘМЕ” РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ИҖАТ ФЕСТИВАЛЕН ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы МБО “Актаныш авыл җирлегеара үзәк китапханә” Гамил Афзал исемендәге “Яшьләр каләме” Республикакүләм фестиваль кысаларында, проза һәм шигырь бәйгесен оештыру һәм уздыру турында игълан итә.

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге нигезләмә, Г. Афзал исемендәге “Яшьләр каләме” Республикакүләм проза әсәрләр һәм шигырь язучылар бәйгесенен максатларын һәм бурычларын, оештыручыларның һәм бәйгедә катнашучыларның хокукларын һәм бурычларын, бәйгене уздыру шартларын, вакытларын, бәйгегә килгән иҗади эшләрне бәяләү критерийларын һәм катнашучыларны бүләкләү шартларын билгели.

1.2. Гамил Афзал исемендәге әдәби Республикакүләм яшь язучылар бәйгесен (алга таба – Бәйге) Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты һәм Актаныш авыл җирлегеара үзәк китапханә муниципаль бюджет оешмасы уздыра.

1.3 Оештыру комитеты Бәйге турындагы мәгълүматны Республика әйдәп баручы китапханәләре – Милли китапханә, Республика балалар китапханәсе сайтлары,

Республика муниципаль районнарының мәгариф идарәләре яки бүлекләре аша мәктәпләргә җибәрелгән мәгълүмат хатлары, массакүләм информация чаралары аша киң җәмәгатьчелеккә җиткерә, шигырьләрне туплауны һәм жюри эшчәнлеген оештыра, бүләкләү тантанасын үткәрә, яшь язучыларның әсәрләрен таныта.

## 2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Гамил Афзалның иҗат мирасын популярлаштыру, иҗатына карата кызыксыну уяту;

2.2. Балаларның һәм яшүсмерләрнең иҗади мөмкинлекләрен үстерү, журналистика, әдәбият, сәнгать, мәдәният өлкәләрендә интеллектуаль иҗат эшчәнлекләрен киңәйтү;

2.3. Татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту;

2.4. Әдәби иҗатка сәләте булган, талантлы балаларны һәм яшүсмерләрне ачыклау, барлау, аларга үзләренең сәләтләрен ачарга мөмкинлек бирү;

2.5. Укучыларны патриотик рухта тәрбияләү, аларда итәгатьлелек, мәрхәмәтлелек, кешелеклелек сыйфатлары формалаштыру.

## 3. Бәйгене оештыру комитеты

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башлыгы;
- Татарстан Республикасы Язучылар берлеге;
- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты;
- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы МБО “Актаныш авыл җирлегеара үзәк китапханә ”;
- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф идарәсе;
- “Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия- интернат” Дәүләт Автономияле гомумбелем учреждениесы;
-“Актаныш-информ” массакүләм - мәгълүмат үзәге;
- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге башкарма комитеты;

- Актаныш муниципаль районы өстәмә белем бирү учреждениесы «Актаныш балалар сәнгать мәктәбе».

## 4.Бәйгене үткәрү шартлары һәм тәртипләре

Бәйге проза һәм шигъри иҗат юнәлешендә дүрт турда уздырыла.

**1 тур** – Һәр район үз җирлекләрендә иҗади бәйгене уздыра һәм бик яхшы дип табылганнарын оештыру комитетына җибәрә.

**2 тур** – Оештыру комитеты тарафыннан билгеләнгән Жюри әгъзаләре (кушымта №1 теркәлгән) килгән барлык иҗади эшләрне тикшереп, сайлап ала һәм йомгаклау өлешенә чакыра.

**3 тур** – Йомгаклау өлеше. “Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия- интернат” Дәүләт Автономияле гомумбелем учреждениесы;

## 5. Катнашучыларга һәм иҗади эшләргә таләпләр

Бәйгедә, Татарстан районнары һәм шәһәрләреннән яшь үзенчәлекләре туры килгән һәркем катнаша ала.

5.1. Бәйгедә татар телендә иҗат итүче балалар катнаша.

5.2. Бәйгегә җибәрелгән эшләр өч яшь категориясенә бүленеп карала:

- 7-9 яшь (кертеп);
- 10-13 яшь (кертеп);
- 14-18 яшь (кертеп).

5.3 Бәйгедә катнашучы, түбәндәге темаларга (өч тема буенча да), берәр шигырь тәкъдим итә. Проза әсәре катнашучының теләге белән түбәндәге темаларның берсенә языла.

-Гамил Афзал үрнәгендә юмор-сатира ;

-милли бизәкләр (халык сәнгате, гореф- гадәт, йолалар)

- Ислам динен кабул итүгә 1100 ел

***Искәрмә: бәйгедә катнашучы бер генә жанрда ( проза яки шигырь) катнаша ала.***

5.4. Бәйге эшләренең бизәлешенә таләпләр: word документы, А4 форматы, Times New Roman шрифты 14.

5.5. Бәйгедә катнашу өчен анкета үрнәге түбәндә (Кушымта №2) күрсәтелгән (бәйге эшләре анкетага теркәп җибәрелә).

***Мөһим өлеш – анкетада бәйгедә катнашучы яшь каләмченең иҗатына кыскача характеристика һәм фотосурәте теркәлгән булу шарт.***

5.6. Бәйгегә җибәрелгән эшләр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый, иң яхшы дип табылганнары җыентыкка туплана.

5.7. Соңарып килгән, югарыда әйтелгән таләпләргә туры килмәгән эшләр, оештыру комитеты тарафыннан кабул ителми һәм каралмый.

## 6.Бәйгене үткәрү вакыты

6.1. Гаризалар 2022 елның 12 апрельдән 12 майга кадәр, электрон форматта **domvet3.bibl@tatar.ru яки rus.rakhimova@yandex.ru** адресы буенча кабул ителә.

6.2. Бәйге эшләрен тикшерү өлеше 2022 елның 13майдан 20 майга кадәр.

6.3. Бәйгенең йомгаклау өлеше 2022 елның 23 май көнендә Актаныш җирлегендә уздырыла.

## 7. Бүләкләү өлеше

7.1. Гамил Афзал премиясын тапшыру.

7.2. Бәйгедә, 3 нче турга узып, беренче өч урынга лаек булган авторларга дипломнар һәм истәлекле бүләкләр, ә калган катнашучыларга рәхмәт хатлары тапшырыла.

## 8. Оештыру комитеты белән элемтәгә керү өчен мәгълүмат

Оештыру комитеты адресы: Актаныш авылы, Тынычлык проспекты 62. Элемтә өчен тел.: 8(85552)3-12-87.

Кушымта №1

**Гамил Афзал исмендәге Республикакүләм бәйгесенең**

**жюри составы:**

1. **Ибрагимов Ильфак Мирза улы** – шагыйрь, Татарстан Республикасы Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.
2. **Моталлапов Әмирҗан Закирҗан улы** - Саҗидә Сөләйманова ис. премия лауреаты, язучы, прозаик, журналистлар һәм Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.
3. **Әминова Ләйсән Галиакбәр кызы** – Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатның татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
4. **Шәрипова Чулпан Рәмзилевна** - Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатның татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
5. **Әхмәтова Рәмзия Шәих кызы** – Актаныш "Агыйдел дулкыннары" берләшмәсе әгъзасы, шагыйрә.
6. **Нажарова Рәфидә Рафаэль кызы** – Актаныш Мәдәният йорты методисты. Атказанган Мәдәният хезмәткәре.
7. **Шадрина Тәэминә Дарвин кызы** – "Актаныш авыл җирлегеара үзәк китапханә" муниципаль бюджет учреждениесы методисты.

Кушымта №2

**Г.Афзал исемендәге “Яшьләр каләме” Республикакүләм иҗади бәйгесендә катнашучы анкетасы**

Бәйгедә катнашучының Ф.И.О.

____________________________________________________________________

Иҗади эшнең жанры (шигырь, проза)___________________________________

Туган елы, көне_____________

Яше _____

Адрес_____________________________________________________________________

____________________________________________________________

Телефон,электрон почта______________________________________________

Фото һәм кыскача иҗади характеристика

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

_____________________________________________________

Бәйгегә тәкъдим ителгән иҗади эшләрнең исемлеге:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

__________________